## 5 нче сыйныф

## Татар әдәбиятыннан тест

## Ел буе өйрәнгәннәрне кабатлау

**1.«Белем алыйм дисәң ничаклы, Сөй, хөрмәт ит, ярат китапны» дигән шигъри юлларны кем язган?**

а) Кол Гали;

ә) Габдулла Тукай;

б) Нәҗип Мадьяров.

**2. Дәреслектә бирелгән картиналарның кайсында иген басуы күренә?**

а) И. Шишкин. «Яңгыр алдыннан»;

ә) И. Левитан. «Июньнең бер көне»;

б) И. Остроухов. «Алтын көз».

**3. Габдулла Тукайның «Су анасы» әсәре буенча нинди балет язылган?**

а) «Шүрәле»;

ә) «Алтын тарак»;

б) «Су анасы».

**4. Фатих Хөснинең «Чыбыркы» хикәясендәге геройның исеме ничек?**

а) Алмаз;

ә) Марат;

б) Рәшит.

**5. «Ак байтал» әкияте нинди әкият төренә керә?**

а) хайваннар турындагы әкият;

ә) көнкүреш әкияте;

б) тылсымлы әкият.

**6. Фәнис Яруллинның «Зәңгәр күлдә Ай коена» әсәрендә Ай нилектән суга баткан?**

а) көчле җилдән;

ә) бака ефәгенә уралганлыктан;

б) дулкыннар кагып.

**7. «Әнә ерак таулар, урманнар, әнә матур гына дулкынланып күренә торган уҗым басуы» дигән юллар кайсы язучының нинди әсәреннән алынган?**

а) Габдулла Тукайның «Туган авыл» шигыреннән;

ә) Галимҗан Ибраһимовның «Яз башы» хикәясеннән;

б) Мөхәммәдьярның «Хикәят» әсәреннән.

**8. Каюм Насыйри кайчан һәм кайда туган?**

а) 1825 нче елда Яшел Үзән районы Югары Шырдан авылында;

ә) 1905 нче елда Оренбург өлкәсе Мостафа авылында;

б) 1886 нчы елда Бишбүләк районы Ает авылында.

**9. Муса Җәлил язган әсәрне билгеләгез.**

а) «Колын»;

ә) «Кыр казы»;

б) «Алтынчәч».

**10. Кайсы әсәрдә Бөек Ватан сугышы сурәтләнә?**

а) Сибгат Хәким. «Колын»;

ә) Мөдәррис Әгъләмов. «Матурлык минем белән»;

б ) Нәби Дәүли. «Бәхет кайда була?»

**Ачкыч**

1. **Ә**
2. **Ә**
3. **Ә**
4. **Б**
5. **Б**
6. **Ә**
7. **Ә**
8. **А**
9. **Б**
10. **А**

# Бәяләү

**9-10 балл – “5”ле**

**7-8 балл – “4”ле**

**5-6 балл – “3”ле**